| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НУРЛАТСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>НОРЛАТ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ
04 сентябрь 2024 ел

КАРАР
169

Физик затлар мөлкәтенә салым кертү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә түләү мәҗбүри булган салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1)-гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән әлеге пунктның 5 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан урыннар;

- һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яисә корылмаларына карата 0,1 процент;

2) фатирларга, фатир өлешләренә, бүлмәләргә карата 0,2 процент;

3) - торак йортлар, торак йортларның өлешләре;

- төзелеп бетмәгән объектларның проектлана торган билгеләнеше торак йорт булган очракта;

- составына бер генә булса да торак йорт кергән Бердәм күчемсез комплексларга карата 0,3 процент;

4) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) карата 1,2% ;

5) - Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата 2 процент;

6) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган салым салу объектларына карата 2,5 процент;

7) салым салуның башка объектларына карата 0,5 процент.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск районы Норлат авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалтуын танырга:

- «Физик затлар мөлкәтенә салым кертү турында» 2014 елның 21 ноябрендәге 187 номерлы карарын;

- Норлат авыл җирлеге Советынын 2014 елның 21 ноябрендәге 187 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында 2015 елның 02 июнендәге 225 номерлы карарын;

- «Физик затлар мөлкәтенә салым кертү турында» 2014 елның 21 ноябрендәге 187 номерлы Норлат авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Норлат авыл җирлеге Советының 2015 елның 02 июнендәге 225 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән). 2015 ел)» 2015 елның 16 октябрендәге 7 номерлы карары

«Физик затлар мөлкәтенә салым кертү турында» 2014 елның 21 ноябрендәге 187 номерлы Норлат авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Норлат авыл җирлеге Советының 2015 елның 02 июнендәге 225 номерлы карары, 2015 елның 16 октябрендәге 7 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) 2018 елның 25 август 148 номерлы карарын;

«Физик затлар мөлкәтенә салым кертү турында» 2014 елның 21 ноябрендәге 187 номерлы Норлат авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Норлат авыл җирлеге Советының 2015 елның 02 июнендәге 225 номерлы карары, 2015 елның 16 октябрендәге 7 номерлы, 2018 елның 25 август 148 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) 2018 елның 16 нояберендәге 162 номерлы карарын;

«Физик затлар мөлкәтенә салым кертү турында» 2014 елның 21 ноябрендәге 187 номерлы Норлат авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Норлат авыл җирлеге Советының 2015 елның 02 июнендәге 225 номерлы карары, 2015 елның 16 октябрендәге 7 номерлы, 2018 елның 25 август 148 номерлы карары, 2018 елның 16 нояберендәге 162 номерлы белән кертелгән үзгәрешләр белән) 2019 елның 12 нояберендәге 200 номерлы карарын;

4. Әлеге карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасы 31.12.2027 елга кадәр гамәлдә булуын билгеләргә.

5. Әлеге карарның 2 пунктындагы 5 пунктчасының гамәлдә булуын 2028 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

6. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интерне» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Арьягы» үзәге бинасы) урнаштырырга.

Норлат авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе И.М.Саттаров